ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.05.2022 г.Лениногорск № 472

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 6 августындагы 309 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм итү өчен Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы (2022 елның 14 мартындагы ред.) Федераль закон нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 6 августындагы 309 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм итү өчен Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Лениногорск муниципаль районы территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм итү өчен Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымтаны төшереп калдырырга;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Субсидия алучыларга карата субсидияләр бирүче Башкарма комитет тарафыннан субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән

аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук РФ Бюджет кодексының 268_1 һәм 269_2 статьялары нигезендә «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ тикшерүләрен гамәлгә ашыру турында нигезләмәләр.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Л.М. Галимова
5-18-52